ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» сентябрь 2019 ел. № 357

**Мөгезле эре терлекләрдәге лейкозны профилактикалау һәм бетерү буенча чикләү-сәламәтләндерү чараларын туктату турында**

«Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 11.05.1999 ел, № 359 боерыгы белән расланган мөгезле эре терлек лейкозын профилактикалау һәм аңа каршы көрәш кагыйдәләре нигезендә, шулай ук “Нәүрүз” ЖЧЖ (Мәүлиев Р. Р.) директорының “Кичкетаң, Яңавыл, Көчек, Үтәгән, Иске Эсләк, Кадыбаш, Тирсә, Кодаш бүлекчәләрендә мөгезле эре терлек лейкозы буенча чикләү чараларын туктату турында” 2019 ел, 29 август, 559 нчы номерлы хатын өйрәнеп, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 14 октябрендәге 244 номерлы карары белән расланган “2010-2012 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында мөгезле эре терлек лейкозы буенча чикләү-сәламәтләндерү чараларының комплексны планы” нигезендә Әгерҗе муниципаль районы территориясендә мөгезле эре терлекләрдәге лейкозны профилактикалау һәм бетерү буенча кичектергесез чараларының тиешле үтәлеше белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң, Яңавыл, Көчек, Үтәгән, Иске Эсләк, Кадыбаш, Тирсә, Кодаш, Тәбәрле («Нәүрүз» ЖЧЖ) бүлекчәләрендә мөгезле эре терлекләрдәге лейкозны профилактикалау һәм бетерү буенча чикләү-сәламәтләндерү чараларын гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р. Р. Гильмутдиновага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А. С. Авдеев**